ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
12.05.2020

КАРАР
№ ПР-89

**«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә югары әзерлек режимын кертү турында» 2020 елның 26 мартындагы ПР-59 номерлы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карары (10.05.2020 ел, №374 үзгәрешләр белән) нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә югары әзерлек режимын кертү турында» 2020 елның 26 мартындагы ПР-59 номерлы карарына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымтада бирелә).
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И.Габдулхаев

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта
12.05.2020 №ПР-89

"Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә югары әзерлек режимын кертү турында”

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә яңа коронавирус инфекциясе (2019-nCoV) таралу куркынычы янауга бәйле рәвештә, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законның $4^1$ статьясы 6 пунктының «б» пунктчасы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 25 мартындагы 206 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карары (10.05.2020 ел, №374 үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, **КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарга үз-үзен изоляцияләү режимын үтәргә, ихтыяҗ булмаган очракта яшәү (тору) урынын калдырып китмәскә, башка гражданнар белән аралашуны максималь дәрәҗәдә чикләргә тәкъдим итәргә.
2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә гражданнар катнашында ял, спорт, күргәзмә, агарту, реклама һәм башка шундый чаралар, шул исәптән паркларда, урман паркларында һәм скверларда, сәүдә һәм күңел ачу үзәкләрендә (комплексларында), аттракционнарда һәм гражданнар күпләп йөри торган башка урыннарда чаралар уздыру рөхсәт ителми.

3. 2020 елның 26 мартыннан Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә түбәндәге эшчәнлекне туктатырга:

- спорт үзәкләре, йөзү бассейннары, кинозаллар, дискотекалар, балалар өчен уен бүлмәләре һәм башка күңел ачу оешмаларында;
- рестораннар, кафелар, ашханәләр, буфетлар, барлар, кабымлыклар һәм башка җәмәгать туклануы оешмаларында, гражданнарның үзләре кермичә, ризыкны чыгарып бирүгә көйләнгән, шулай ук заказлар китерүче оешмалардан тыш.
- даруханә һәм даруханә пунктларыннан тыш, ваклап сату объектларының, шулай ук беренче чиратта кирәкле, азык-төлек булмаган товарлар сату өлешендә сәүдә залының мәйданы, килүчеләр өчен кулай булган, 400 кв. м. га кадәр, аерым тышкы (урам) керү мөмкинлеге булганда, товарларны дистанцион ысул белән сату, шул исәптән китереп бирү шарты белән, ваклап сату объектларының эше;
- гражданның турыдан-туры катнашуын күздә тоткан мунча, сауна һәм башка объектлар.

4. Гражданнарга дини объектларга йөрүдән тыелырга тәкъдим итәргә.
5. Санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчы, тыярга:

- тарту өчен кальяннар бирү буенча хезмәт күрсәтү, кальяннарны үз территорияләрендә куллану;
- гражданнарның ваклап сату, хезмәтләр күрсәтү объектларында, пассажирлар һәм багаж ташуны, шул исәптән таксины да кертеп, транспорт чараларында, шулай ук гражданнарның шәхси саклану чараларын кулланмыйча җәмәгать урыннарында булуы (битлекләр, ресираторлар);
- гражданнарның ваклап сату объектларында, пассажирларны һәм багажны, шул

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карарына 2 нче кушымтада күрсәтелгән 65 яшьтән өлкәнрәк яшьтәге яисә авыру булган гражданнарга түбәндәге искәрмәләрдән тыш, яшәү (тору) урыныннан китмәскә тәкъдим итәргә:

- ашыгыч (кичектергесез) медицина ярдәме һәм башка турыдан-туры янау очраклары өчен мөрәҗәгать итү;
- эш урынына бару һәм кире кайту мөмкинлеге булмаган очракта, дистанцион формага күчерү;
- товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуның якында урнашканына бару;
- кешеләр күпләп була торган урыннардан тыш, яшәү (тору) урыныннан 100 метрдан артмаган арада йорт хайваннарын чыгару һәм йөртү;
- калдыкларны якын арада урнашкан җыю урынына кадәр чыгару;
- дачага бару (шәһәр читендәге йортка) яки дачадан кайту (шәһәр читендәге йорттан).

7. Санитар-эпидемиологик хәлне яхшырту өчен 14 календарь көн эчендә өйдә үз-үзеңне изоляцияләүне тәэмин итүне йөкләргә:

- Россия Федерациясе субъектлары территориясеннән килгән (кире кайткан) гражданнар;
- Россия Федерациясе субъектлары территорияләреннән килгән (кайткан) гражданнар белән изоляцияне тәэмин итү чорында бергә яшәүче гражданнар.

Әлеге пунктта күрсәтелгән, беренче респиратор симптомнары күренгән затлар, медицина оешмаларына кермичә, кичекмәстән медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итәргә тиеш.

8. «Татмедиа» ААҖ филиалы "Актаныш мәгълүмат - мөхәррият үзәге" директорына ММЧ да яктыртырга:

– яңа коронавирус инфекциясен профилактикалау буенча тәкъдимнәр (2019-nCoV);

9. Әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган йогышлы авыруларны таратуга китерә торган, яисә күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешү куркынычы тудыра торган йогышлы чир таралуга китерә торган гамәл кылу/гамәл кылмау өчен җаваплылык турында кисәтү.

10. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И.Габдулхаев